ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.03.2025 № 283

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы милкендәге һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләүне кичектереп тору срогын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 20 августындагы 959 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы, «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясенең 18.02.2025-29гр номерлы хатына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы милкендәге һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәткә түләүне кичектереп тору срогын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 20 августындагы 959 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы милкендәге һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган арендалана торган мөлкәт өчен сигез ел һәм күчемле мөлкәт өчен өч ел түләүне кичектереп тору срогы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисенә йөкләргә.

Җитәкче А.К. Габдуллин